# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## "Алабуга" ирекле икътисадый зонасы турында

Әлеге Закон "Алабуга" ирекле икътисадый зонасын төзүнең, аның эшчәнлегенең һәм аны бетерүнең хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләрен билгели.

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1 статья. Әлеге Законда кулланылучы төп төшенчәләр

Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

"Алабуга" ирекле икътисадый зонасы (алга таба - Ирекле икътисадый зона) - инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлегенең әлеге Закон белән билгеләнүче махсус хокукый һәм икътисадый режимы гамәлдә булган чикләнгән территория.

Ирекле икътисадый зонаның администрациясе - дәүләт учреждениесе статусына ия булган, Ирекле икътисадый зонага идарә итүне тормышка ашыручы оешма.

Ирекле икътисадый зонаның күзәтү советы Ирекле икътисадый зона администрациясенең эшчәнлеген координацияләүче һәм тикшереп торучы орган булып тора.

Ирекле икътисадый зона операторы - Ирекле икътисадый зона максатларына ирешү һәм бурычларын хәл итү өчен төзелгән, Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан вәкаләтләр бирелгән юридик зат.

Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды - Ирекле икътисадый зона администрациясенең икътисадый программаларын финанслау

өчен Ирекле икътисадый зонаның махсуслаштырылган фонды.

Рөхсәт - Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру хокукына Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан бирелә торган документ.

Ирекле икътисадый зонада катнашучы - рөхсәте булган, Ирекле икътисадый зонада катнашучылар реестрына кертелгән, инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыручы юридик зат.

<u>2 статья</u>. Ирекле икътисадый зонаны төзү һәм аның эшчәнлеге тәртибе

"Алабуга" ирекле икътисадый зонасы, әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасының Алабуга районында урнашкан Алабуга сәнәгать мәйданы территориясендә гомуми мәйданы 16,5 кв.км итеп төзелә.

Ирекле икътисадый зонада Ирекле икътисадый зонада катнашучы буларак теркәлгән юридик затларга бирелүче инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлегенең аерым, өстенлекле ташлама режимы билгеләнә.

Әлеге Законда каралган өстенлекле салым ташламалары, шулай ук валютаны җайга салу өлкәсендәге өстенлекле ташламалар һәм таможня зонасының Россия Федерациясе законнарында билгеләнүче таможня режимын урнаштыра торган шартлар инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлегенең аерым режимы дип аңлашыла.

Ирекле икътисадый зона, киләчәктә законнарда каралган тәртиптә озайтылу хокукы белән, егерме биш елга төзелә.

<u>3 статья.</u> Ирекле икътисадый зона төзүнең максатлары һәм бурычлары

Ирекле икътисадый зона Татарстан Республикасында инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген уңышлы тормышка ашырырга ярдәм итүче уңай хокукый, инвестиция, салым режимын булдыру өчен төзелә.

Ирекле икътисадый зонаны төзү түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

- Татарстан Республикасында конкуренциягә сәләтле җиңел автомобильләр чыгару куәтләре булдыру өчен инвестицияләр җәлеп итүне;
- эчке базарны импортны алыштырырлык, шул исәптән автомобиль төзелешендә кулланылучы продукция белән баетуны;
- экспортка чыгаруга юнәлтелгән җитештерү булдыруны;
- халыкның эш белән тәэмин ителешен арттыруны;
- конкуренциягә сәләтле җитештерү һәм эшкуарлык инфраструктурасы булдыруны.

## II бүлек. Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеге режимы

### 4 статья. Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген хокукый җайга салу

Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган башка норматив хокукый актлар нигезендә тормышка ашырыла.

### 5 статья. Ирекле икътисадый зонада таможня режимы һәм валюта җайга салуы

Ирекле икътисадый зонада ирекле таможня зонасының таможня режимы Россия Федерациясенең таможня законнары белән билгеләнә һәм җайга салына.

Ирекле икътисадый зонада валюта операцияләрен җайга салу Россия Федерациясе законнары нигезендә тормышка ашырыла.

### 6 статья. Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды

Ирекле икътисадый зона Администрациясенең икътисадый программаларын финанслау Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды тарафыннан тормышка ашырыла.

Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды турындагы нигезләмә

Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Ирекле икътисадый зонаны үстерү фонды түбәндәгеләр исәбеннән булдырыла:

- Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеге хокукына Рөхсәтләр бирүдән килгән керем;

- Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның әлеге Закон нигезендә башкарылучы түләүләре;

- Федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасының Республика бюджетыннан бирелүче акчалар;

- Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан законнарга туры китереп шартнамә нигезендә җәлеп ителүче предприятиеләр һәм оешмалар акчалары;

- финанслауның законнарда тыелмаган башка чыганаклары.

<u>7 статья.</u> Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның түләүләре

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар Ирекле икътисадый зонаны үстерү фондына түбәндәге түләүләрне кертәләр:

- Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасыннан файдаланган өчен читтән кертелә торган товарлар бәясеннән ике процент һәм читкә чыгарыла торган товарлар бәясеннән ике процент күләмендә;

- җир кишәрлекләрен арендалаган һәм хезмәт күрсәтүләр өчен.

Түләүләрнең вакыты, тәртибе һәм күләмнәре, Ирекле икътисадый зонаның эшчәнлеге үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве беренче ун ел эчендә арттырылмаска тиеш һәм аннан соңгы ун ел эчендә ике тапкырдан да арттырыла алмый.

"Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе, аның юридик зат хокукына ия булган структур бүлекчәләре, түләнми калган акчаларны Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасы үсешенә юнәлдергән очракта, Ирекле икътисадый зона инфраструктурасыннан файдаланган өчен Ирекле икътисадый зона үсеше фондына түләүләрдән 2005 елга кадәр азат ителәләр.

"АлАЗ-ДМ" Корпорациясе, Ирекле икътисадый зонаны үстерү фондына җиңел автомобильләр җитештерүне оештыру һәм куәтләр булдыруга күчерелә торган өлешендә, Ирекле икътисадый зона инфраструктурасыннан файдаланган өчен түләүләрдән 2005 елга кадәр азат ителә.

8 статья. Ирекле икътисадый зонада өстенлекле салым ташламалары

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегенә, Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына, дәүләт социаль һәм медицина иминләштерүенә түләүләрдән кала, Татарстан Республикасы бюджетына барлык төр салым түләүләреннән һәм җыемнардан, Татарстан Республикасының бюджеттан тыш дәүләт фондларына түләүләрдән азат ителәләр.

Ирекле икътисадый зонада катнашучыларга өстенлекле салым ташламалары бары тик Ирекле икътисадый зона территориясендә башкарылучы эшчәнлек өлешендә генә бирелә. Катнашучыларның Ирекле икътисадый зона территориясеннән читтәге эшчәнлегенә салым салу гомуми нигезләрдә законнарга туры китереп башкарыла.

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар законнар нигезендә Россия Федерациясе тарафыннан билгеләнүче өстенлекле салым ташламаларыннан файдаланалар.

9 статья. Ирекле икътисадый зона администрациясенең вәкаләтле банкы

Ирекле икътисадый зонада катнашучыларга банк хезмәте күрсәтүне Күзәтү советы карары белән конкурс нигезендә билгеләнә торган Ирекле икътисадый зона администрациясе Вәкаләтле банкы (моннан ары Вәкаләтле банк) тормышка ашыра. Вәкаләтле банк белән Ирекле икътисадый зона администрациясе арасындагы мөнәсәбәтләр шартнамә белән билгеләнә.

Ирекле икътисадый зонаның Вәкаләтле банкы билгеләнгәнче Ирекле икътисадый зонаның үсеш фонды акчалары Күзәтү советы күрсәткән банкка урнаштырыла.

153



10 статья. Ирекле икътисадый зонаны идарә итү

Ирекле икътисадый зонаны идарә итүне Ирекле икътисадый зона администрациясе гамәлгә ашыра. Администрация эшчәнлегенә оператив идарәне Татарстан Республикасы Президенты билгеләгән Ирекле икътисадый зона администрациясе башлыгы тормышка ашыра.

Ирекле икътисадый зона администрациясе турында нигезләмә Татарстан Республикасының Министрлар кабинеты тарафыннан раслана.

Ирекле икътисадый зона администрациясенең төп эшчәнлеге түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

- Ирекле икътисадый зонаның үсеш программасын эшләү һәм әлеге программаны тормышка ашыру мониторингы;

- Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеге хокукына Рөхсәтләр бирү;

- Ирекле икътисадый зонаның инфраструктурасын төзү һәм аның функцияләвен тәэмин итү;

- җитештерү, склад, транспорт, хезмәт биналарын һәм башка биналарны, корылмаларны проектлаштыруны һәм төзүне оештыру һәм алардан файдалануны тикшереп тору;

- Ирекле икътисадый зонада катнашучылар белән җир кишәрлекләрен, биналарны, җитештерү һәм склад тибындагы корылмаларны арендалау (субарендалау) шартнамәләрен төзүгә булышлык итү;

- ирекле икътисадый зонада катнашучыларның үзләре кабул иткән йөкләмәләрен аларга рөхсәтләр биргәндә, шул санда рөхсәтләрне туктатып торганда яисә аларны юкка чыгарганда үтәлешен тикшереп тору;

- Ирекле икътисадый зонаның эшчәнлеге турында дәүләт идарәсе органнарына аларның вәкаләтенә кергән мәсьәләләр буенча хисап бирү;

- дәүләт хакимияте һәм идарәсе органнары һәм җирле үзидарә органнары белән мөнәсәбәтләрдә Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның мәнфәгатьләрен тәкъдир итү;

- Ирекле икътисадый зонаны үстерү фондын, кредит һәм иминләштерү оешмаларын төзүгә һәм аларның эшчәнлегенә, булышлык итү;

- Ирекле икътисадый зонада түләүләр алуны һәм Ирекле икътисадый зона фонды акчаларының максатчан тотылышын тикшереп тору.

Ирекле икътисадый зона администрациясе Ирекле икътисадый зона территориясендә катнашучыларның инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыру хокукы реестрын, шулай ук юкка чыгарылган һәм туктатылган рөхсәтләр реестрын алып бара.

Ирекле икътисадый зона администрациясенә Ирекле икътисадый зонада урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенә идарә итү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү вәкаләте бирелә.

<u>11 статья</u>. Ирекле икътисадый зонаның Күзәтү советы

Ирекле икътисадый зона администрациясе эшчәнлеген Ирекле икътисадый зонаның Күзәтү советы җайга сала һәм тикшереп тора.

Ирекле икътисадый зона Күзәтү советы Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган Нигезләмә буенча эш итә.

Ирекле икътисадый зона администрациясе башлыгы, Алабуга шәһәре һәм Алабуга районы администрациясе башлыгы һәм "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсе генераль директоры эш урыннары буенча Күзәтү советы әгъзалары булып торалар.

Ирекле икътисадый зонаның Күзәтү советы Татарстан Республикасы Премьер-министры тарафыннан җитәкләнә.

<u>12 статья</u>. Ирекле икътисадый зона операторы

Ирекле икътисадый зона операторы - законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслый торган Нигезләмәгә таянып, "Алабуга җиңел автомобильләр заводы" җитештерү берләшмәсенә беркетелгән мөлкәт өлеше базасында төзелүче, Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан вәкаләт бирелгән юридик зат.

Ирекле икътисадый зона операторы Ирекле икътисадый зона эшчәнлеге өчен шартлар тудыра һәм Ирекле икътисадый зона максатларына ирешүдә һәм бурычларын хәл итүдә Ирекле икътисадый зона администрациясенә ярдәм итә.

13 статья. Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибе

Ирекле икътисадый зона территориясендә инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлегенең законнар билгеләгән, рөхсәт алуны күздә тоткан тәртибе гамәлдә була.

Рөхсәт җитештерү өлкәсендә инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашырган, шулай ук Ирекле икътисадый зонада җитештерү эшчәнлеген тормышка ашыру өчен кирәк булган банк, иминләштерү, транспорт-экспедиторлык һәм башка хезмәтләр күрсәтүче юридик затларга бирелә.

Ирекле икътисадый зонада рөхсәтләр бирү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты раслаган Нигезләмә белән билгеләнә.

Рөхсәт бирү өчен түләү күләме Ирекле икътидасый зона администрациясе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм биш ел буе үзгәртелми.

Ирекле икътисадый зонада катнашучыларның үзләренә алган йөкләмәләрен үтәмәүләре, катнашучыларның бу йөкләмәләрне үтәгәнче, рөхсәтнең гамәлдә булуын Ирекле икътисадый зона администрациясе тарафыннан туктатып торылуына, яисә, әгәр аның үзләре генә чишә алмаслык хәлләр аркасында килеп чыгуы исбат ителмәсә, катнашучылар реестрыннан төшереп калдырып, бу рөхсәтнең юкка чыгарылуына китерә.

14 статья. Ирекле икътисадый зонада җир кишәрлекләреннән һәм башка күчемсез объектлардан файдалану хокукы

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар Ирекле икътисадый зона территориясендә урнашкан җир кишәрлекләреннән һәм башка күчемсез объектлардан файдалану, шул исәптән законнар нигезендә төзелгән шартнамәдә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда озак вакытка арендалау (субарендалау) шартларында файдалану хокукына ия.

Инвестцияләрнең күләмен 10 миллион АКШ долларына тиң суммадан күбрәк билгеләгән Ирекле икътисадый зонада катнашучы, инвестицияләр күләменең 50 процентын тормышка ашырганнар соң,

Ирекле икътисадый зона территориясендә урнашкан, үзе файдалана торган мөлкәтне милек итеп алу хокукына ия була.

15 статья. Ирекле икътисадый зона территориясендә экологик иминлек һәм әйләнә-тирә табигать мохитен саклау

Ирекле икътисадый зона территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлек өлкәсендәге мөнәсәбәтләр Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар белән җайга салына.

Ш бүлек
Ирекле икътисадый зонага керү һәм Ирекле икътисадый зонадан чыгу һәм аның территориясендә булу тәртибе.
Ирекле икътисадый зонада социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре

16 статья. Ирекле икътисадый зонага керү, Ирекле икътисадый зонадан чыгу һәм аның территориясендә булу тәртибе

Ирекле икътисадый зонага керү, Ирекле икътисадый зонадан чыгу һәм аның территориясендә гражданнарның, шул исәптән чит ил гражданнарының һәм гражданлыксыз затларның булуы тәртибе законнар белән билгеләнә.

Ирекле икътисадый зона территориясендә физик затларның даими яшәве рөхсәт ителми.

17 статья. Ирекле икътисадый зонада социаль-хезмәт мөнәсәбәтләре

Ирекле икътисадый зонада хезмәт мөнәсәбәтләре хезмәт турындагы законнар белән җайга салына.

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар хезмәткәрләрне эшкә алу һәм азат итү, хезмәт һәм ял режимы, хезмәт хакын түләү шартлары, гарантияләр һәм компенсацияләр мәсьәләләрен мөстәкыйль хәл итәләр. Бу очракта предприятиедәге хезмәткәрләрнең хәлен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган

законнарда каралган шартлар белән чагыштырганда начарайту тыела.

Эшче һәм хезмәткәрләр составына, Ирекле икътисадый зонада катнашучы оешмалар белән идарә итү органнарына чит ил гражданнары керә ала. Чит ил хезмәткәрләрен эшкә алу, ял һәм хезмәт, шулай ук пенсия белән тәэмин итү шартлары, аларның һәркайсы белән аерым хезмәт шартнамәләрендә (контракларда) килештерелә. Чит ил хезмәткәрләре алган хезмәт хакы, керем салымы алынганнан соң, чит ил валютасында чит илгә күчерелергә мөмкин.

Ирекле икътисадый зона территориясендә җитештерү һәм төзү-монтаж эшләре башкару өчен җәлеп ителүче чит ил эшчеләренең саны Ирекле икътисадый зона администрациясе белән килештерелә.

Ирекле икътисадый зона территориясендә тиешле квалификациядәге эшләрне башкару өчен чит ил инженер-техник һәм идарә итү персоналын җәлеп итү чикләнми.

Ирекле икътисадый зонада социаль һәм медицина иминләштерүе һәм хезмәткәрләрне социаль тәэмин итү, чит ил хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итүдән кала, Татарстан Республикасы территориясендә гамәлдә булган законнар белән җайга салына.

Чит ил хезмәткәрләрен пенсия белән тәэмин итү өчен түләүләр алар даими яшәгән илләрнең тиешле фондларына валютада һәм әлеге ил куйган шартларда күчерелә.

## IV бүлек.
## Йомгаклау нигезләмәләре

<u>18 статья</u>. Ирекле икътисадый зонаны бетерү

Ирекле икътисадый зонаны бетерү Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты тарафыннан әлеге Закон нигезендә башкарыла.

Ирекле икътисадый зона түбәндәге нигезләрдә бетерелергә мөмкин:

а) Ирекле икътисадый зона төзелгән чорның тәмамлануы;

б) әлеге Законда каралган максатларны тормышка ашыруның мөмкин булмавы, ләкин бу зона төзелгәннән соң кимендә биш ел үткәч кенә;

153



в) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы иминлеге мәнфәгатьләреннән чыгып.

Әлеге статьяның б) һәм в) пунктларында күрсәтелгән очракларда Ирекле икътисадый зонада инвестиция һәм эшкуарлык эшчәнлеген тормышка ашыру буенча үз йөкләмәләрен килешү нигезендә үтәүче Ирекле икътисадый зонада катнашучыларга, әгәр Ирекле икътисадый зонаны бетерү турында карар кабул итү көненә рөхсәт вакыты узмаган булса, китерелгән зыян законнар нигезендә түләтелә.

<u>19 статья</u>. Әлеге законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыга торган бәхәсләрне хәл итү

Әлеге Законны куллануга бәйле рәвештә килеп чыга торган бәхәсләр законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

Ирекле икътисадый зонада катнашучылар милкен национализацияләү яисә реквизицияләү очрагында компенсация түләвенең күләме, шартлары яисә тәртибе турында бәхәсләр, әгәр Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә башкача каралмаса, законнар нигезендә карала.

<u>20 статья</u>. Әлеге Законны гамәлгә кертү тәртибе

Әлеге Закон матбугатта басылып чыккан көненнән гамәлгә кертелә.

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетына ике ай вакыт эчендә әлеге Закон нигезендә норматив хокукый актлар кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Президенты
М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1998 елның 22 апреле
N I569